КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 май г.Казань № 304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә Украина территориясендә, шулай ук реакция бирүнең максималь һәм уртача дәрәҗәләре кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә яшәүче, торак урыннарын мәҗбүри калдырып киткән Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә Украина территориясендә, шулай ук реакция бирүнең максималь һәм уртача дәрәҗәләре кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә яшәүче, торак урыннарын мәҗбүри калдырып киткән Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, ның 30 апрель, 406 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 883 нче, 2023 ел, 21 гыйнвар, 30 нчы, 2023 ел, 12 август, 973 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә Украина территориясендә, шулай ук реакция бирүнең максималь һәм уртача дәрәҗәләре кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә яшәүче, торак

урыннарын мәҗбүри калдырып киткән Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| «12. | Биектау муниципаль районы | Казан шәһәренең «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча «Ял» шәһәр үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе, «Яшьләр» ел әйләнәсе сәламәтләндерү лагере. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин